| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2025 п.г.т.Алексеевское № 512

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 30.12.2022 ел, №585 «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«2023-2025 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын финанслау күләмнәре үзгәрүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 11.11.2025 ел, № 2549-р күрсәтмәсенә туры китереп;

**карар бирәм:**

1.Башкарма комитетның 30.12.2022 №585 «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карары белән расланган «2023-2025 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына (алга таба Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Программаның «Программаны финанс белән тәэмин итү» 6 нчы бүлеген таблица белән тулыландырырга (Кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_25.11.2025 ел, № _512_
карарына кушымта

| № т/б | Чара исеме | Финанс чыгымы (Республика бюджеты) мең сум. |
|---|---|---|
| | | 2025 |
| 1. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алуга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ | 195,49 |
| 2. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алуга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кышкы спорт төрләре спорт мәктәбе» ӨББ МБУ | 33,36 |
| | Барлыгы | 228,85 |